МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН
УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ МР ЕРМЕКЕЕВСКИЙ РАЙОН
МОБУ СОШ с. УСМАН-ТАШЛЫ

НАУЧНО-ИССЛЕДОВАТЕЛЬСКАЯ РАБОТА

# КОНЦЕПТ «ЖИЗНЬ» В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

(на татарском языке)

Выполнила: Миннуллина Айгуль Салаватовна
учитель татарского языка и литературы
МОБУ СОШ с.Усман-Ташлы

2016 г.

# Эчтәлек

Кереш..............................................................................................................3-5 б.

Төп өлеш

I Бүлек. Лингвистикада лингвокультурология фәне һәм аның төп аңламнары:

1.1. Лингвокультурология турында гомуми төшенчә.................................6-8 б.

1.2. “Дөнья картинасы” турында өйрәтмә................................................9-10 б.

1.3. Концепт терминаның бүгенге лингвистикадагы урыны..................11-13 б.

1.4. Концептуаль анализлау үзенчәлекләре............................................14-16 б.

II Бүлек. Татар тел дөнья күренешендә “гомер” концептының чагылышы:

2.1. Татар телендә “гомер” компонентының мәгънә үзенчәлекләре......17-18 б.

2.2.Татар һәм рус теленең мәкаль-әйтемнәрендә “гомер” концепты....19-22 б.

2.3. “Гомер” концептының поэтик текстларда чагылышы......................23-26 б.

Йомгак.............................................................................................................27-28 б.

Кулланылган әдәбият исемлеге................................................................29-30 б.

## Кереш

Кеше тирә-якны танып белү белән бергә үзенең яшәеше: материаль һәм рухи дөньясы белән кызыксына. Кеше вербаль аң белән характерлана. Икенче төрле әйткәндә, без киләчәк эш-хәрәкәтләрне сүз, җөмләләр ярдәмендә күз алдына китерәбез. Халык яки аерым шәхеснең рухи тормышын сүзләр аша тикшерү белән лингвокультурология фәне шөгыльләнә.

Лингвокультурология XX гасырның 90 елларында гына барлыкка килү сәбәпле, рус культурасын тикшерә башласа да, татар халкының теле белән рухи тормышын бәйләп өйрәнүче хезмәтләр бүгенге көндә бик аз. Тел аша культураны өйрәнү А.Брюкнер, В. Иванов, В.Топоров, Н. Толстой тарафыннан кузгатылган булган [26, б.13]. Хәзерге көндә бу юнәлештә В.Н. Телия, Ю.С. Степанов, Н.Д. Арутюнова, В.В. Воробьева, В. Шаклина кебек фразеологик мәктәп әгъзаларының фәнни эшләре лингвокультурологиянең бүгенге үсешен тәшкил итә. Лингвокультурология фәненең төп аңламнары булып “дөньяның тел картинасы”, “концепт” терминнары тора. Бүгенге көндә бу терминнарның төгәл билгеләмәсе юк.

Конңептларны тикшерүнең төп методы - конңептуаль анализ. Ләкин “конңептуаль анализ” сүзтезмәсе үзе үк ике мәгънәле: ул конкрет конңептларны анализлауны да, художестволы текстны конңептлар ярдәмендә анализлауны да аңлатырга мөмкин. Фәнни-тикшеренү эшендә без бу ике төр анализны да карап үтәбез.

Функциональ яктан, мәдәният өчен әһәмиятле шагыйрьләрнең иҗатында, ягъни конкрет поэтик текстлар эчендә әлеге конңепт тикшерелмәгән. Бу уңайдан бүгенге татар милли дөнья картинасында “гомер” конңептының тоткан урынын күзаллау өчен Башкортостан һәм Татарстан республикаларында укучылар һәм тәнкыйтьчеләр ягыннан танылу алган, үз әсәрләрендә бүгенге чынбарлыкны сурәтләүче язучылар – Нәҗибә Әминева, Рим Идиятуллин иҗатына мөрәҗәгать итү урынлы дип танылды.

Югарыда әйтелгәннәр фәнни-тикшеренү эшенең **<u>актуальлеген</u>** билгели.

Фәнни-тикшеренү эшенец **проблемасы** - татар милли дөнья картинасында “гомер” концепты нинди урын тота, шагыйрьләрнең шәхси дөнья күренешендә әлеге концепт ни дәрәҗәдә чагыла һәм ничек интерпретацияләнә дигән сорауларга җавап эзләү.

Куелган проблемаларны хәл итү фәнни-тикшеренү эшенең **максаты** булып тора.

Фәнни-тикшеренү эшенең тикшерү **объекты** - тел белемен өйрәнүдә лингвомәдәни тошенчәләр; **предметы** - татар дөнья тел күренешендә “гомер” коннцепты.

Фәнни-тикшеренү эше түбәндәгене фараз итүгә нигезләнә: татар тел һәм художестволы дөнья картинасында “гомер” концептының репрезентацияләнү үзенчәлекләрен өйрәнү, аңа салынган үзәк һәм перифериялрне, төшенчә һәм коннотаңия кырларын билгеләү, концептның шәхси-индивидуаль өлешен ачыклау татар халкыныц, шул исәптән аерым язучы-шагыйрьләрнең дә, дөньяга карашлар системасын, эстетик һәм этик принңипларын күзаллау мөмкинлеген бирә.

Фараз итү, максат, проблема фәнни-тикшеренү эше алдында торган **бурычларны** тәгаенли:

1. Лингвокультурология турында гомуми карашларны күзәтү;

2. Лингвокультурология фәненең төп аңламы булган “дөнья картинасы” төшенчәсен ачыклау;

3. Татар милли тел дөнья күренеше нигезләрен күзәтү;

4. Лингвокультурология фәненең төп аңламы булган “коннцепт” төшенчәсенең бүгенге лингвистикада аңлатмаларын өйрәнү;

5. Татар һәм рус телендә “гомер” концептының мәгънә үзенчәлекләрен ачыклау;

6. Татар һәм рус телендә “гомер” компоненты булган мәкаль-әйтемнәрне тикшерү;

7. Татар тел дөнья күренешендә “гомер” концептының урынын һәм характерын ачыклау;

8. “Гомер” концептының шигъри текстларда чагылышын анализлау.

Куелган бурычларны үтәү очен түбәндәге тикшерү методлары кулланылды:

1. Теоретик әдәбиятны өйрәнү һәм анализлау;

2. Чагыштырма анализ;

3. Текстны интерпретацияләү;

4. Концептуаль анализ.

Фәнни-тикшеренү эшенең **<u>чыганаклары</u> :** Нәҗибә Әминеваның (“Гомер дигән мизгелдә”, “Жаным илһамлы чакта”), Рим Идиятуллинның (“Хәерле кич”) җыентыклары.

Фәнни-тикшеренү эшнең **<u>методологик һәм теоретик нигезләрен</u>** Ю.С. Степанов, В.А. Маслова, Р.Р. Җамалетдинов, С.А. Аскольдов, Д.С. Лихачев һ.б. хезмәтләре тәшкил итә.

Фәнни-тикшеренү эшенең теоретик һәм практик **<u>әһәмияте:</u>** концепт теориясенә булган карашларны системалаштыруда, “гомер” лингвокультурологик концептының татар милли дөнья тел картинасында тоткан урынын, әлеге концептның аерым шагыйрьләр тарафыннан интерпретацияләнүен ачыклауда.

Фәнни-тикшеренү эше кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

## Төп өлеш.

## I Бүлек. Лингвистикада лингвокультурология фәне һәм анын төп аңламнары

### 1.1. Лингвокультурология турында гомуми төшенчә

Хәзерге лингвистикада телнең аерым бер система икәнлеге кире кагылмый, ләкин аны чикләнгән автоном күренеш итеп кенә өйрәнү дөрес түгел, аны кешенең яшәү һәм эшләү өлкәсенең бер өлеше итеп өйрәнергә кирәк.

Элек яшәп килгән системалы-структуралы парадигма урынына антропоцентрик парадигма килә. Лингвистларның кызыксыну өлкәсе телнең структурасыннан аның кулланылыш шартларына күчә. Е.С. Кубрякова әйтүенчә, антропоцентризмда фәнни объектлар аларның кеше өчен ролендә, кеше яшәвендә башкарган функциясе ягыннан тикшерелә [26, б.21].

Перспективалы юнәлешләрнең берсе - лингвокультурология. Ул лингвистика һәм культурология чигендә барлыкка килгән. Лингвокультурология милли телдә гәүдәләнеш тапкан материаль һәм рухи культураны ойрәнә.

Лингвокультурология бурычлары - тел һәм культура, тел һәм этнос, тел һәм милли менталитетны өйрәнү һәм тасвирлау. Объекты - тел һәм культураның функцияләү барышындагы бәйләнешен тикшерү. Тикшерү предметлары күптөрле: 1) лингвострановедение предметы - эквивалентсыз лексика һәм лакуналар; 2) телдә теркәлгән мифлашкан тел берәмлекләре: архетип һәм мифологемалар, йола һәм ышанулар, гореф-гадәтләр; 3) телнең паремиологик фонды; 4) телнең фразеологик фонды; 5) эталон, стереотип, символлар; 6) телнең метафора һәм образлары; 7) телләрнең стилистик тәртибе; 8) сөйләм тәртибе; 9) сөйләм этикеты өлкәсе [26, б.30].

Лингвокультурология үзәгендә тел һәм культураны үзендә йөртүче буларак кеше тора. Фәнни әдәбият исбатлаганча, теләсә кайсы этносның мәдәниятен өйрәнү эшен бик күп тематик юнәлешләрне үз эченә алучы

“кеше” төшенчәсеннән башка хәл итү мөмкин түгел. Татар лингвомәдәнияте үзенчәлекләрен, менталитетын ачыклауда түбәндәге аспектлар аеруча зур әһәмияткә ия: кешенең көнкүреш шартлары, аның рухи эчке дөньясы, хис-тойгы һәм кичерешләре.

Галимнәр фикеренчә, фәннең антропологик нигезләрендә түбәндәге үсеш юллары торырга мөмкин:

1) Антропологик парадигма якынлашу юлы буларак карала: кеше теориягә кертелми, тел җанландырыла, мифлаштырыла.

2) Телне “үз-үзендә” түгел, ә “кеше өлеше” буларак карау тәкъдим ителә.

3) Тикшерү предметы - телгә ия булу аспектында өйрәнелүче кеше.

4) Тел кешенең конструктив үзенчәлеге буларак интерпретацияләнә, ә кеше булып нәкъ тел аша билгеләнә [12, б.7].

Антропологик юнәлешле лингвистика кысаларында беренче планга лингвогносеология (когнитология), лингвосоциология, лингвопсихология, лингвоэтнология, лингвопалеонтология, лингвокультурология кебек юнәлешләрне өйрәнү куела. Америка лингвисты Г.Б. Пальмер аңламында “культуралы лингвистика” когнитив лексика белән этнолингвистиканың төрле традицияләрен кушып бирә [8, б.8].

Бүгенге көндә лингвокультурологиядә берничә юнәлешне аерып күрсәтергә мөмкин:

1) аерым социаль группа, этнос лингвокультурологиясе;

2) диахроник лингвокультурология, ягъни этносның билгеле бер чорда лингвокультура торышы үзгәрешен өйрәнү;

3) чагыштырма лингвокультурология, төрле, ләкин үзара бәйләнгән этносларның лингвокультурасы ачылуын тикшерә;

4) лингвокультурологик лексикография, лингвистика күзлегеннән илләрне өйрәнү сүзлекләрен чагыштыру [26, б.28].

Дөнья күренеше теге яки бу этнос теленең эчтәлегендә чагыла. Аны анализлау милли мәдәниятләрнең аермаларын, дөнья мәдәнияте дәрәҗәсендә бер-берсен ничек тулыландыруын аңларга ярдәм итә.

Шагыйрьләр теге яки бу милли мәдәниятнең гәүдәләндерүчесе булганлыктан, аның когнитив структурасына милли дөнья картинасы да йогынты ясый. Ә ул исә индивидуаль үзләштерү призмасы аша интерпретацияләнә һәм тел чаралары аша гәүдәләндерелә. В. Гумбольдт буенча, тел "милли рухны" гына түгел, аерым шәхеснең дөньяны концептуализацияләү үзенчәлеген дә чагылдыра. Шулай итеп, дөньяның тел картинасы һәм поэтик текстлар материалында төзелүче дөнья күренеше үзара бәйләнешле.

В.А. Маслова "дөньяның поэтик картинасы" терминын аерып чыгара. Рухи байлыкнын төп саклаучысы булып матур әдәбият әсәрләре тора. Алар авторның эчке дөньясын һәм аның аңы аша үткәрелгән тышкы дөньяны чагылдыра. Шулай итеп, дөньяның поэтик картинасы туа. Бу объектив дөньяның субъектив образы.

Дөньяның тел картинасы универсаль, ә поэтик картинасы -индивидуаль, ул бер кеше, халыкның бер вәкиле текстларында туа. Дөнья күренеше күпкатлы: гомумкешелек дөнья күренешеннән индивидуальгә.

Дөньяның поэтик картинасы индивидуаль, субъектив, образлы. Язучы шәхесе - аның яшәешенең чагылышы. Мондый дөнья картинасы чынбарлык дөньяның альтернативасы буларак аңлана. Бу авторның теле һәм аң призмасы аша төзелгән дөнья образы. Культура телдә вербальләшә, ә тел милли үзаң турында мәгълүматны үз эченә ала, ул милли рухны, язучының дөньяны концептуализацияләү үзенчәлекләрен дә чагылдыра. Концептуаль һәм тел дөнья картиналары белән бәйле поэтик текстлар поэтик дөнья картинасының репрезентациясе булып тора.

Алдагы бүлектә без татар милли дөнья тел күренешен тасвирлау омтылышын ясап карыйбыз.

## 1.2. “Дөнья картинасы” турында өйрәтмә

Милли дөнья тел күренешен тасвирлауга күптөрле галимнәр мөрәҗәгать итә. Р.Р. Җамалетдинов татар дөнья тел күренешен күзалларга омтыла, ләкин гомуми тел картинасы белән эш итә. Дөньяның концептуаль күренеше дөньяның тел картинасы аша формалаша. Татар дөнья моделен ачыклау Р.Р. Җамалетдинов хезмәтләрендә тулысынча хәл ителми, анда бары гомуми фикерләр яктыртыла: татар дөнья күренешенә бәйле татар халкының яшәү рәвеше, матди дөньясы, соңиаль мөнәсәбәтләре һ.б. Бу татар дөньясының тулы картинасын бирүче әйберләр түгел, ләкин берникадәр күзалларга мөмкинлек бирә.

Милли дөнья тел күренешенең нигезендә һәрбер этносның җәмгыяти-тарихи тәҗрибәсендә, аның этник культурасында ятучы аермалыклар бар. Төрле телдә сөйләшүче һәм төрле культура вәкилләре булган кешеләр чынбарлыкны төрлечә күрә һәм бәялиләр.

“Дөнья картинасы” термины физик галимнәр телендә XIX-XX гасыр чикләрендә барлыкка килә. Тел гыйлеменә исә ул Л. Вайсгербер тарафыннан кертелә. XX гасыр азагында бу проблемага багышланган бик күп хезмәтләр барлыкка килә, мәсәлән, Н.Д. Арутюнова, Ю.Д. Апресян, А. Вежбицкая, С.А. Васильева, Г.В. Колшанский, Н.И. Сукаленко, Ю.С. Степанов, В.Н. Телия, В.Г. Гак, М. Блэк, Д. Хайнс һ.б. хезмәтләре. Л. Вайсгербер фикеренчә, һәр этник җәмгыять дөньяны үзенчә үзгәртә.

Һәр халыкның дөньяны күзаллавы дөнья картинасына җыела. А.Я. Гуревич сүзләре белән әйтсәк: “һәр цивилизация, һәр соңиаль система үзенә генә хас дөньяны танып-белү ысулы белән характерлана” [26, б.36]. Һәр табигый тел үзенә генә хас конңептуализацияләү ысулын чагылдыра. Телнең төп конңептлары бердәм карашлар системасына, ягъни дөнья характеристикасына җыела. Бу - тарихи формалашкан конкрет халыкның конкрет телдәге дөнья образы.

“Дөнья тел картинасы” төшенчәсе лингвокультурологик тикшеренүләрнең актуальлеге сәбәпле киң кулланылышта, бу исә терминга төгәл билгеләмә бирүне һәм чиктәш терминнардан, мәсәлән “донья моделе”, аеруны таләп итә. Моның өчен аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итергә була.

“Картина” сүзенең мәгънәләрен карау әлеге төшенчәнең әһәмиятле үзенчәлекләрен аерып чыгарырга ярдәм итә.

С.И. Ожегов сүзлегендә “картина” сүзе “күрергә, күзәтергә, тел образларында күзалларга була торган нәрсә”, “нәрсәнең дә булса күренеш, халәт, торышы” мәгънәсендә. Рус теленең зур сүзлегендә бу мәгънәгә “берәр нәрсәнең якты һәм тәэсирле сүз сурәте” дигән мәгънә өстәлә [7, б.419], ә сурәт исә – “тышкы” дөньяның предмет һәм күренешләрен аң ярдәмендә тергезүе” [7, б.682].

Шулай итеп, “дөньяның тел картинасы - тирә-як чынбарлыкның предмет һәм күренешләре турында күрсәтмәле күзаллау төзүче дөнья сурәте” [14, б.25]. Нәтиҗәдә дөньяның тел картинасы - тирә-як чынбарлыкның предмет һәм күренешләрен тел чаралары ярдәмендә телдә торгызуы. Картина бердәм чагылышны күз уңында тота, ул чынбарлыкны сәнгать картинасы кебек чагылдыра. Дөньяны аның чиксез күпьяклылыгы һәм бердәмлегендә чагылдырып, дөньяның тел картинасы шул картинаны төзүче күренешләрне, аларның халәт, торышын, бер-берсенә карата мөнәсәбәтен чагылдыра.

Татарларның дөнья турындагы күзаллауларының аерым фрагметлары татар дөнья тел күренешендә ничек гәүдәләнеш табуын ачыклау барышында, мәҗүси ышанулар калдыклары һәм меңъеллык ислам традицияләренә бәйләнгән дөнья күренеше, кыйммәтләр системасы йогынтысы белән очрашырга мөмкин.

## 1.3. Концепт терминаның бүгенге лингвистикадагы урыны

Коннцепт термины лингвистика фәнендә бер үк вакытта яңа да, иске дә. С. Аскольдов-Алексеев үзенең 1928 елда бастырылган “Концепт һәм сүз” мәкаләсендә коннцептлар табигате мәсьәләсен иске дип ассызыклап үткән. Ул концептка мондый билгеләмә бирә: “Коннцепт уйда барлыкка килгән һәм фикерләү барышында бер төрдән булган күп төрле предметларны алыштыра”.

С.А. Аскольдов коннцептны өйрәнүдә өч төп юнәлешне аерып күрсәтә. Идеалистик һәм интуитивистик юнәлештәге гносеологлар еш кына концептларның аң оешмалары буларак яшәп килүен кире кагалар. Алар өчен концепт - объектив яшәеш, ягъни дөнья чынбарлыгы нигезендә ятучы гомумилек. Әлеге юнәлешнең йомшак ягы - кешенең предметларга субъектив карашын чагылдыручы ясалма табигатле концептларның күплеген аңлау һәм аңлату мөмкинлеге булмауда [2, б.268-269].

Беренче караш вәкиле Ю.С. Степанов игътибарны культурологик аспектка юнәлткән, ә культура коннцептлар җыелмасы һәм аларның үзара бәйләнеше буларак билгеләнә. Концепт - кешенең менталь дөньясында төп мәдәни оя. Коннцептлар - Европа культурасының бер өлеше. Алар коллективның тел аңында төп урын алып торалар, шуңа күрә аларны өйрәнү актуаль проблемага әверелә. Концептның мондый аңламында телнең роле икенчел, ул ярдәмче чара гына - культураның “телләштерү” формасы.

Аерым кешенең сүзлек запасында ачыкланган яшерен мөмкинлекләрнең барысын бергә Д.С. Лихачев коннцептосфера дип атый. [26, б.282]. Бу терминны галим В.И. Вернадскийның ноосфера, биосфера терминнары тибы буенча кертә. Коннцептлар җыелмасын Ю.С. Степанов белән В.П. Нерознак исә коннцептуаль өлкә дип билгелиләр. Кайбер галимнәр концептуаль система терминын кулланалар.

Бер коннцептосфера икенчесе белән ярашырга мөмкин, мәсәлән, тулаем бер тел коннцептосферасы, аның эчендә инженер - практик коннцептосферасы, аныц эчендә гаилә коннцептосферасы, аның эчендә индивидуаль коннцептосфера [24, б. 282].

Концептлар кешеләрнең индивидуаль тәҗрибәсендә генә барлыкка килми һәм барлык кешеләр бертигез дәрәҗәдә милли тел коннцептосферасын баету мөмкинлегенә ия түгел. Концептосфераны барлыкка китерүдә язучылар (бигрәк тә шагыйрьләр), фольклор ияләре, аерым профессия һәм сыйныф кешеләре мөһим урынны алып торалар, дип исәпли Д.С. Лихачев.

Коннцептосферага шулай ук үз мәгънәләре аша коннцептлар тудырган әсәр исемнәре дә керә.

Тел концепты һәрчак вербальләшкән була. Әгәр концептны вербализацияләү тәмамланмаса, димәк танып-белү процессы да тәмамланмаган. Танып-белү акты исемләштерү белән тәмамлана, ягъни нәтиҗәдә концептның тел билгесе (языковой знак) туырга тиеш [14, б.76]. С.В. Иванова фикеренчә, сүз тууы концепт формалашуы процессын тәмамлый.

Галим тел коннцепты астында вербальләшкән асылны аңларга тәкъдим итә. Вербализация тотрыклы тел берәмлегендә объективлаштырылган булырга, ә ул тел берәмлеге танып-белү процессын тел билгесе яисә грамматик категориядә беркетергә тиеш. Сүз, телдә барлыкка килеп, үз “коннцептуаль тарихын” булдыра башлый, ягъни ул әлеге төшенчә белән бәйле күзаллауларның, ассоциацияләрнең барлыкка килү юлы буенча бара, бирелгән лингвомәдәни берләшмәнең тел донья күренешендә яшәп килүче берәмлекләр белән бәйләнешкә керү ярдәмендә үз урынын эзли. Нәтиҗәдә әлеге процесс менталь кичерешләрнең сөземтәсе буларак тәмамлана.

Концепт объект яки күренешнең төп, асыл үзенчәлекләрен чагылдыра. Коннцепт табигате комплекслы характерда булуы сәбәпле лингвист өчен авырлык тудыра. Концептка лингвистик һәм экстралингвистик белемнәр кушыла. Аның лингвистик өлеше мәгънә, лексема һәм потенциаль семема белән тиңләшә. Концептның когнитив аңлатмасы иң элек аның менталь табигатен ачыклый. Концептны когнитив интерпретацияләү аның чикләренең төгәл түгеллеген дә ачыклый.

Әдәби текстта китерелгән автор концептлары составына прецедентлы текст концептлары да керә. Ю.Н. Караулов билгеләвенчә, прецедентлы текстлар – ул “теге яки бу шәхес очен танып-белүле һәм эмоциональ мөнәсәбәттә әһәмиятле булган һәм шәхестән өстен характерга ия текстлар”. Кеше аңында когнитив структурага, иерархик җыелмага оешып прецедентлы текст концептлары дөнья картинасы фрагментын барлыкка китерә. Башка конңептлар кебек, үк автор концептлары катлам һәм кырлары арасында анык булмаган чикле катламлы-кырлы структурага ия. Концептныц катламлы структурасы аның үзәк, үзәк яны, периферия зоналарыннан торуында чагыла.

Концептның үзәге гомум кабул ителгән төшенчәләр, билге һәм ассоциацияләрдән тора, дөнья күренешенең гомуммилли өлешен гәүдәләндерә. Концептныц периферия зонасы шәхси билгеләрдән, эмоция, образ һәм ассоциацияләрдән тора һәм дөнья картинасының индивидуаль өлешен тәшкил итә.

Концептның катламлы структурасы аның төшенчәле (фактуаль), билге (кыйммәти-билгеле) һәм ассоциатив (образлы-ассоңиатив) катламнарга ия булуында чагыла.

А.Я. Гуревич фикеренчә, һәрбер дөнья моделендә, этник үзенчәлекләр белән бергә, үзара бәйләнгән универсаль аңламнар бар: вакыт, кицлек, үлчәү, сәбәп, язмыш, сан һ.б. Концептлар җыелмасы бер булса да, һәрбер халыкның үзенә генә хас концептлар бәйләнеше дөньяга караш нигезен тәшкил итә. Концептларны тикшерүнең төп методы - концептуаль анализ. Киләсе бүлекнең максаты - концептуаль анализлауның асылын ачыклау.

## 1.4. Концептуаль анализлау үзенчәлекләре

Лингвокультурологиядә фәннәр нигезен өйрәнү һәм тел материалын гамәли яктан анализлау бер үк вакытта алып барылганлыктан, аның алдында үзенең тикшерү методларын ачыклау мәсьәләсе тора. Р.Р. Җамалетдинов фикеренчә, “лингвомәдәни анализның төп принциплары” әлегә формалашу стадиясендә генә [13, б.81]. Аның нигезен когнитив анализ, психоанализ, сүзне семантик анализлау, контент-анализ, тикшеренүче тупланган фактик материалны синхрон-диахрон яктырту методы тәшкил итә. Әмма фәнни юнәлешне институтлаштыру өчен аның үз тикшеренү предметы һәм шулай ук үзенең фәнни-тикшеренү методлары булуы шарт.

Лингвокультурологик тикшеренүләр бүгенге көндә берничә нигезгә таяна. Тикшеренүнең гамәли аспектлары иң элек лингводидактика белән бәйләнә. В.В. Воробьев фикеренчә, лингводидактикадагы лиңгвокультурологик метод комплексды тикшеренү методы булып тора, аның ярдәмендә телне чит тел буларак адекват куллануның лингвистик һәм культурологик тәэмин ителеше ачыклана [13, б.82].

Лингвокультурологик тикшеренүләрдә “концепт” термины раслану белән концептуаль анализ дип аталган фәнни тикшеренү формасы барлыкка килә. Концептуаль анализ - концептларны тикшерүнең төп методы. Әмма “концептуаль анализ” дигәндә, концептларны анализлау да, әдәби текстныц соңгы берәмлекләренә әвереләдерелгән анализ да, әдәби текстның концептуаль анализы да аңлашылырга мөмкин.

Н.И. Толстой күрсәткәнчә, “мәгънә мәсьәләсенең алга таба үстерелеше ике капма-каршы юнәлештә бара: төзү һәм мәгънә төрләренә бүлгәләү юнәлешендә һәм берләштерү, сүзнең бөтен семантик өлкәсен тулаем күзаллау юнәлешендә” [13, б.82]. Сүзнең мәгънәсен тулаем тасвирлау мәсьәләсе мәгънәнең барлык баскычлары арасындагы эчке бәйләнешләрне ачыклаудан, сүзнең образлылыгы “логикасын”, билгеле бер телдә сөйләшүчеләр аңында сүзгә йөкләнгән һәм алар тарафыннан бик җиңел “укылган” төрле реаль һәм потенциаль “мәгънә-дәлилләрне” ачыклаудан гыйбарәт.

Лингвокультурологиядә концептуаль анализны куллану бу фәнни юнәлешнең интегратив характеры белән, тел структурасын гына тасвирлаудан антропоүзәкчел тасвирлау юнәлешенә борылу омтылышы белән аңлатыла.

Теоретик лингвокультурологиядә В.М. Шаклеинның лингвомәдәният ситуациясен тарихи-ретроспектив өйрәнү методы белән очрашырга мөмкин, В.Н. Телиянең "фразеологик телне" лингвокультурологик анализлау методы да актив кулланыла.

Мәдәният концептларын В.Н. Телия тарафыннан тәкъдим ителгән конңептуаль-географик анализлау түбәндәге этаплардан гыйбарәт: этнос мәдәният концептын билгеләү очен кулланган берәмлекләрне (лексик, фразеологик һ.б.) ачыклау; концептны өлешләп параметрлаштыру; концептуаль кыса төзү һәм аңа концептны номинаңияләү ысулларын йөкләтү; таксономик челтәрләрнең "сәламәт акылы" нигезендә һәр параметрның эчендә концептны аерып алу һәм нигез метафораны этносныц мәдәният стереотибы белән чагыштыру [13, б.83].

Бүгенге концептуаль анализ методлары турында сөйләгәндә, тикшеренүчеләрнең күпчелеге тарафыннан танылган төп теоретик нигезләмәләрне атарга мөмкин: конңептуаль пространствоның һәр милли тел өчен мөһимлеге, тел һәм мәдәният бәйләнеше, телнец мәдәният концептлары өлкәсенә кертелүе.

Хәзерге көндә мәдәният концептларын тасвирлауның күп төрле лингвокультурологик методикалары турында әйтергә мөмкин. Әлеге методикалар, үз номинацияләрендә тикшерелүче тел материалын, яисә үткәрелүче анализның төп моментларын чагылдырып, төрле атамаларга ия.

Концептуаль анализ компонентларны җентекләп өйрәнүгә нигезләнергә мөмкин, чөнки семантик билгеләр комбинациясен ачыклау, тикшерелүче концептуаль зурлыкларның телдәге мәгънә континуумында урынын билгеләп, аларныц эчтәлек күләмен ачу өчен җирлек барлыкка китерә, башка конңептлар арасында аларны танырлык итә.

Лексемаларны концептуаль анализлау барышында сүзлек дефиницияләрен анализлау методы кулланылырга мөмкин. Әлеге метод сүздә һәм аның аңлатмасында кешенең когнитив эшчәнлеге нәтиҗәләре туплануы турындагы күзаллауга нигезләнә. Билгеле бер телдә сөйләшүче кешеләр, кагыйдә буларак, үз белемнәрен сүзлек дефинацияләре белән туры китереп тормыйлар, әмма сүзлек аңлатмасы сүз белән белдерелгән концепт спектрын ачыктан-ачык күрүдә, лексеманың когнитив структурасын ачыклауда бердәнбер мөмкинлек булып тора [13, б.84]. Концептны ачыклау өчен, сүзнең лексик мәгънәсен анализлау үткәрелә. Ул, тиешле категориаль аппаратны кулланып, когнитив семантика принципларына нигезләнеп башкарыла. Әлеге юнәлеш кысаларында сүз мәгънәсе реаль ситуациядән аның турында сөйләүгә күчү турындагы караштан чыгып ачыла [13, б.84].

Конкрет концептларны анализлауның төгәл схемасы, эзлекле алгоритмы булмау сәбәпле, диплом эшендә “гомер” коннептын анализлауда да төрле алымнар кулланылды: компонентлы анализ, дефиницияләү, этимологик анализ, концептны репрезентацияләүче синонимик берәмлекләрне анализлау, синтагматик бәйләнешләрне, семантик күчерүнең төп типларын ачыклау, персонификация, специфик образларның булу-булмавын, концептның лексик репрезентаңияләрен ачыклау, татар фразеологизмнарында, мәкальләрендәге репрезентацияләрне, тексттагы идивидуаль-автор интерпретаңияләрен анализлау.

Концептларны билгеле бер милли дөнья тел күренешендә карау бу милләт тел күренешендә аның тоткан урынын, аңа нинди мәгънәләр салынуын ачыкларга ярдәм итә. Алдагы бүлек - шуныц турында.

## II Бүлек. Татар тел дөнья күренешендә “гомер” конңептының чагылышы

### 2.1. Татар телендә “гомер” компонентының мәгънә үзенчәлекләре

“Кеше” суперконңептының үзәген тәшкил итүче конңепт – “гомер”нең татар телендә репрезентаңияләнү дәрәҗәсен ачыклау халыкның яшәү-үлү, яшәү мәгънәсе кебек фәлсәфи карашлар системасын ачыкларга мөмкинчелек бирә.

Татар телендә “ут”, “моң”, “сагыш” кебек конңептлар тикшерелгән, алар буенча диссертаңия эшләре эшләнгән. Ә “гомер ” концепты, мәсәлән, әлегә тиклем тикшерелмәгән иде.

“Гомер” – алынма сүз булуга карамастан, татар теле тарафыннан тирән үзләштерелгән . Моңа дәлил рәвешендә сүзнең мәгънәләрен ачыклыйк.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә “гомер ”нең 5 мәгънәсе бирелә:

1. Барлык тереклек иясенең туу моментыннан алып үлгәнгә кадәр булган физиологик хәле, яшәү вакыты.

2. Кешенең гомерендә була торган билгеле бер чор.

3. Вакыт, вакытның бер өлеше.

4. рәв. мәг. күч. юклык формасында фигыль янында: беркайчан да, бервакытта да.

5. рәв. мәгъ. күч. гомергә: мәңге, мәңгегә, гомер буена, бик озак вакытта.

С.И. Ожегова, Н.Ю. Шведованың “Рус теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә “гомер”нең (“жизнь”) алты мәгънәсе бирелә:

1. Совокупность явлений, происходящих в организмах, особая форма существования материи.

2. Физиологическое существование человека, животного, всего живого.

3. Время такого существования от его возникновения до конца, а также в какой-нибудь его период.

4. Деятельность общества и человека в тех или иных ее проявлениях.

5. Реальная действительность.

6. Оживление, проявление деятельности.

Димәк, татар һәм рус халкында гомер **кеше, вакыт, мәңгелек** төшенчәләре белән тыгыз бәйләнә, ләкин, гомумән әйткәндә, “гомер” ул – туганнан алып үлгәнгә кадәр булган чор.

Алынма сүз булуына карамастан, *гомер* югары ешлыкка, күпмәгънәлелеккә ия; актив лексика; актив җитештерүче нигезле сүз (*гомер-гомергә, гомеренчә, гомерле, гомерлек, гомерлелек*). *Гомер* бер составлы атау җөмләнең баш кисәге, шигырь исеме була ала.

*Гомер* лексемасының синтагматик бәйләнешләре киң: *гомер – үтә, ага, бетә, уйландыра,сүнә...; гомер – бәхетле, бәхетсез, озын, кыска, үкенечле, моңлы, кайгылы...; гомер – халык (гомере), кеше, иҗат, җыр, яшьлек...; гомер – язы, козе, кышы, таңы, иртәсе, киче.*

Синонимнар сүзлеге нигезендә “гомер”нең синонимик рәте төзелде. Ф.С. Сафиуллина фикеренчә, бер үк яки якын мәгънә белдергән сүзләр төркеме синонимик рәт барлыкка китерә. Бу рәтләрдәге беренче сүзләр бөтен рәттәге сүзләр өчен уртак төшенчә белдерә һәм төп сүз (доминанта сүз) дип атала. Безнең очракта доминанта булып, “гомер ” тора.

“Гомер”дә тормыш һәм яшәеш тә, мәңгелек һәм аерым бер чор да, кеше язмышы һәм туудан үлемгә кадәр яшәү вакыты да чагыла. Сүзнең мәгънә катламнары киң һәм бай. Ул татар теленең үз концептына әверелгән дип әйтә алабыз.

## 2.2. Татар һәм рус теленең мәкаль-әйтемнәрендә "гомер" концепты

Донья тел картинасын анализлау өчен паремияләрне, ягъни мәкаль һәм әйтемнәрне анализлау мөһим дип исәплиләр. Шуның өчен без "гомер" компоненты булган мәкаль һәм әйтемнәрне җыю һәм тикшерү максатын куйдык. Халык аваз иҗаты арасында әдәби эстетик кыйммәте буенча һәм сан ягыннан төп урынны, һичшиксез, мәкальләр алып тора. Татар фольклоры җыентыкларында басылган һәм фәнни фондларда туплпанган мәкальләр саны, төрле вариантларын кертеп исәпләгәндә ике мең чамасына җитә.

Мәкаль атамасы безгә гарәп теленнән кергән. Аның мәгънәсе "сөйләү, әйтеп бирү" дигәнгә туры килә. Жанр исеме буларак бу сүз татар фольклористикасы тарихында беренче мәртәбә М. Ивановның "Татарская хрестоматия" дәреслегендә очрый. Мәкальләрне өйрәнү фәннең күп кенә тармакларында эшләүче галимнәрнең, бигрәк тә фольклорчыларның һәм лингвистларның, игътибар үзәгендә тора. Мәкальне бәяләүдә аларның карашында шактый якынлык күзәтелә. Фольклорчылар да, телчеләр дә мәкальнең төгәлләнгән җөмләдән торуын, образлы булуын, тормыш тәҗрибәсен гомумиләштереп, билгеле бер нәтиҗә, хөкем чыгаруын, гыйбрәт, үгет-нәсихәт өчен, ягъни дидактик максатта әйтелүен, сөйләмгә матурлык һәм тәэсирлеклелек бирүен күрсәтәләр.

Паремияләрне өйрәнү, беренчедән, мәдәният белән билгеләнгән телдәге мәгънәләрне ачыкларга, икенчедән, аеруча мөһим мәдәни стереотипларны формалаштыруның когнитив алымнарын карарга мөмкинлек бирә [13. б.124].

Халык иҗатында мәкаль кайсы вакытларда барлыкка килгән? Бу сорауга, әлбәттә, фәлән гасырда дип конкрет җавап бирү мөмкин түгел. Барыннан да элек, биредә ярдәмгә мәкальләр үзләре киләләр. Алар арасындагы эчтәлекләрне белән турыдан-туры ыруглык оешмасы тормышын, андагы гореф-гадәтләрне, йола-ышануларны чагылдырган әсәрләрне очратып була. Татар (төрки) халык мәкальләренең моннан күп гасырлар элек туа башлаган

булуы кайбер язма чыганаклар белән документаль рәвештә дә дәлилләнә. Мәсәлән, 1907 елда Көнчыгыш Төркстандагы Дуньхуан монастыре китапханәсендә унике мәкаль тексты теркәлгән. Белгечләр бу кулъязманың язылу вакытын унынчы гасырның икенче яртысы белән билгелиләр.

Күп гасырлар буе татар халкы үзенең якын күршеләре руслар, башкортлар, чувашлар, удмуртлар, һ.б. халыклар белән хуҗалык көнкүрештә һәм рухи тормышта күп төрле элемтәләргә кереп, "тел, лөгать вә әхлак" һәм акыл хикмәт җәүһәрләрен алмашып яшәп килә. Безнең фольклор хазинәсендә бу халыклардан да кергән мәкальләрнең булуы табигый хәл.

Мәкальләрнең эчтәлегендә тормышның барлык яклары, катлаулы тарихи иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән алып гади көнкүреш детальләренә кадәр, бик тулы чагылыш тапкан. Иҗтимагый тормыш циклына керүче мәкальләрдә шәхес һәм коллектив, дуслык дошманлык, ил-дәүләт булып яшәү, хөкем һәм идарә итү, сыйнфый каршылыклар кебек җитди темалар күтәрелә.

"Гомер" концепты татар һәм рус теленең мәкаль-әйтемнәрендә чагылыш таба. Татар, рус халык менталитетында "гомер" компонентлы мәкаль-әйтемнәр милли дөнья картаинасының бер өлешен тәшкил итә. Н.С. Исәнбәтнең "Татар халык мәкальләре китабын "да (2 том) "гомер" белән 78 берәмлек бирелә.

"Гомер" концептының мәкаль-әйтемнәрдәге мәгънә төсмерләре өйрәнелде. Тупланган паремияләр лексик-семантик яссылыкта тикшерелде һәм 6 төркем ачыкланды, аларга лексик-семантик классификация үткәрелде.

1. Мәңгелектә вакыт чагылышы:

*а. Гомернең узганы юк, күлмәгенең тузганы юк; б. Сәгать-сәгать газиз гомер үтеп бара, вакыт үтсә, бу гомергә юктыр чара; в. Гомер озын да, сәгать кыска.*

2. Яшәү чорлары:

*а. Гомер итү, гомер кичерү,гомер үткәрү, гомер буе, гомер бакый; б. Гомер таңы; в. Гомер күзе.*

3. Гомер сыйфатлары:

*а. Озын гомерле буласың килсә, халыкка вәгъдәгә мал; б. Озак гомер итәр өчен акрын гомер итәргә кирәк; в. Үткән гомер – аккан су, яки искән җил; г. Үткән гомер – калган салават; д. Эшсез гомер – утсыз гомер; е. Эш булсын дигән кеше юк, гомер үтсен дигән кеше күп.*

4. Мирас:

*а. Аталардан мирас – баһасыз гомер, яндырмыйча агач булмас күмер.*

5. Кешегә хас төп сыйфатлар:

*а. Кеше дөньяда ничаклы гомер итсә дә туймый; б. Кеше гомере – су өстендәге ак күбек; в. Кеше гомере төшкән чык кебек; г. Әдәм гомере – оч кон.*

6.Яшәү мәгънәләре:

*а. Гомерне заяга уздыру; б. Гомер юлы такыр булмый; в. Күп уйлаган – гомерен бушка уздырган; г. Күңеле киңнең гомере рәхәт үтә.*

Әлеге лексик-семантик төркемне аңлатмалы сүзлектә бирелгән мәгънәләр белән чагыштырганда, монда "гомер" концептының мәгънә төсмерләре баерак булуы күренә: мәсәлән, **гомер-мирас, гомер-яшәү** кебек аңламнар мәкаль-әйтемнәрдә күзәтелә. Бу факт, беренчедән, "гомер" сүзенең, алынма булуына карамастан, татар халкы тарафыннан семантик планда күптән һәм тирән үзләштерелгәнлеге хакында сөйли, икенчедән, дөнья тел картинасында татар халкының яшәү фәлсәфәсен чагылдыручы төп берәмлекләрнең берсе буларак кабул ителә.

С.И. Ожегова, Н.Ю. Шведованың "Рус теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә "гомер"нең ("жизнь") алты мәгънәсе бирелә. Шушы билгеләмәләр ярдәмендә рус теленең мәкаль-әйтемнәре буенча 7 тематик төркем төзелде. Барлыгы 141 "гомер" компоненты кергән мәкаль-әйтем анализланды:

1.Үлем: а) *живой смерти не ищет; б) жил долго, а умер скоро;*

2. Бөтен тереклекнең яшәеше: а) *жизнь прожить - не поле перейти; б) живи и надейся;*

3. Алла: а) *жить – Богу служить; б) живи не как хочется, а как Бог велит;*

4. Гасыр: *а) век живи, век учись;* б) *век протянется, на всякого достанется;*

5. Яшәешнең төрле юллары: *а) не тот живет больше, кто живет дольше; б) живи для людей, поживут и люди для тебя;*

6. Яктылык: а) *свет не наскучит; б)жизнь, что солнечная вода, чем больше пьешь, тем больше жажда;*

7. Терелү, хәрәкәт итү: *а) жизнь идет, как по маслу.*

Бу квалификация ярдәмендә " гомер"нең яңа мәгънәләре ачыла. Иң күп мисал **гомер–үлем** төркеменә карый. Монда гомергә ике яклы караш ачыла. Мәсәлән, *"живой смерти боится" – "исән үлемнән курыкмый" , "живой смерти не ищет" – "исән кеше үлем эзләми", "живой в могилу не ляжет"- "исән гүргә ятмый"* кебек мисалларда кешенең үлемнән куркуы күренә.

Шулай итеп, тикшерелгән мисаллардан күренгәнчә, татар һәм рус телендә "гомер" компоненты кергән мәкаль-әйтемнәр күп: 78 һәм 141. Татар телендә "гомер" сүзе алынма булуына карамастан, өстәмә коннотацияләр белән баетылган, мәкаль-әйтемгә әверелерлек дәрәҗәдә семантик планда халык тарафыннан күптән үзләштерелгән. Татар теленең мәкаль-әйтемнәрендә "гомер" концептында "мәңгелек" мәгънәви өлеш шактый зур. Бу концепт "яшәү мәгънәсе, яшәү сыйфаты, кеше сыйфаты" кебек аңламнарны да үз эченә сыйдырган. Татар мәкаль-әйтемнәрендә гомернең буыннардан тапшырылган мирас булуы, аңа сакчыл караштa яшәү идеясе дә еш чагыла. Рус теленең мәкаль-әйтемнәрдә "гомер " еш кына "үлем" белән параллель рәвештә бирелә, "гомер" һәм "Алла" бәйләнеше дә күзәтелә, "гомер"гә "яктылык" мәгънәсе дә салынган. Шулай да ике тел өчен дә уртак аңламнар өстенлек иткән мәкаль-әйтемнәр күпчелек.

"Гомер" сүзенең кулланылу ешлыгы, лексик-семантик вариантлары булуы аның татар һәм рус дөнья тел күренешендә гаять мөһим урын алып торуын раслый.

## 2.3. “Гомер” концептының поэтик текстларда чагылышы

Без үзебезнең фикерләребезне җөмләләр белән белдерәбез. Шулай сөйләм барлыкка килә. Язылган, бастырылган сөйләм текст була. Текстагы җөмләләр мәгънәви, логик, коммуникатив, структур-грамматик, интонацион яктан оешалар. Текст ул – мөстәкыйль җөмләләрнең билгеле бер рәвештә оешуы. Аерым җөмләләр текст эчендә генә яшиләр, текст эчендә генә сөйләмгә кереп китәләр. Аларның барлык мәгънәләре текст эчендә генә ачыла.

Поэзия термины поэзия теориясен генә түгел, иҗат практикасын да күздә тота. Поэтика - әдәби әсәрләрнең төзелеше һәм аларда файдаланылган эстетик чаралар системасы хакындагы фән. Поэтика составында теоретик (гомуми) һәм тарихи поэтикаларны аералар. Теоретик поэтика әдәби әсәрнең тозелеш законнарын һәм әдәби чараларны өйрәнү белән шөгыльләнә. Аның кысаларында фоника, стилистика һәм топика яшәп килә. Фониканың өйрәнү предметы булып әсәрнең аваз составы тора. Стилистика - поэтик лексика, морфология һәм синтаксисның; топика исә образлар, мотивлар, сюжетларның үзенчәлекләрен өйрәнә.

Поэтик текстларда без “гомер” артында традиңион мәгънә белән бергә индивидуаль-автор мәгънәләрен дә ачыклый алабыз. “Гомер” конңепты артында яткан гомуми һәм индивидуаль мәгънәләрне билгеләү өчен без шигъри текстларга мөрәҗәгать иттек. Бу максат белән без ***Нәҗибә Әминеваның*** (“Гомер дигән мизгелдә”, “Жаным илһамлы чакта”), ***Рим Идиятуллинның*** (“Хәерле кич”) китапларын тикшердек.

**Нәҗибә Әминева** – гомер буе туган авылында татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән кеше. Нәҗибә Әминева шигырьләре – тормышның үзе, күпләребезнең күңелендә яткан гап–гади уй–фикерләрнең гүзәл һәм оста чагылышы. Шагыйрәнең әсәрләренә фикер тирәнлеге, зирәк фәлсәфә, кыю чагыштырулар, көтелмәгән образлылык хас. Шигырьләре тормыш, үлем, яшәү мәгънәсе, илһам, сүз көче турында.

Нәҗибә Әминева поэзиясен халык яратып өлгерде, чөнки ул халыкның

зирәклегенә, халык традицияләренә тугры булып кала. Яхшылык, яктылык, мәхәббәт белән йөртелгән нечкә лирикада аның көче.

Әйтеп киткәнчә, Н. Әминева шигырьләре тормыш, яшәү–үлем, кеше гомере турында. "Гомер" концепты шагыйрә иҗатының төп өлешен биләп тора. Аның шигырьләрендә кеше гомере фәлсәфәсе ярылып ята. Бер китабының исеме үк, күреп үтүебезчә, шуңа ишарә. Нәҗибә Әминеваның җыентыгыннан без барлыгы "гомер" компоненты кергән 50 мисал тупладык. Бу мисаллар тулысынча беренче кушымтада күрсәтелгән.

Кешенең яшәве сәяхәтне хәтерләтә. Кеше йөри–йөри сәяхәт итә, алда ниләр барын, ниләр күрәчәген белми, уйламый ул. Кеше бүгенге дөньяда үзеннән башка берни күрми, шуңа күрә дөньяның, язмышыбызның кайда юл тотканын без үзебез дә белмибез.

Кешенең гомере өч фасылдан тора: сабыйлык, яшьлек, картлык:

*Гомернең сабыйлык, яшьлек*
*Кебек бер чоры картлык.*
*Шатлык түгел. Тик гомердә*
*Кайсы чор - тоташ шатлык.* [3, б.92]

Кеше гомеренең иң самими, иң кызыклы, мавыктыргыч чоры – сабыйлыктыр. Һәр аткан таң, һәр нәрсә – синең өчен яңалык. Син бар нәрсәне дә беренче тапкыр күрәсең, синең өчен болар барысы да ят. Ләкин дөнья сине шул вакытта да елатырга өлгерә.

*Сабыйлык чорыннан башлап*
*Елыйбыз да көләбез.* [3, б.92]

Җырларда җырланган, шигырьләрдә данланган – яшьлек. Аңа тиң әйбер юк. Яшьлек – шат чак.

Бу ике фасыл бик тиз үтеп китә. Телисеңме, теләмисеңме – сине картлык көтә. Картлык - моңсу чак. Ләкин "мәгънәле моңсулык" , шуңа картлык - кызыклырак. Бу чорны сабыйлык, яшьлек кебек үк "матур мәл" итү үзеңнән тора түгелме соң?

*Итеп булмасмы картлыкны*
*<u>Гомернең</u> матур мәле?..*
*Итәргә иде картлыкны*
*Ничектер матур һәм шәп.*
*Итәргә дә, матур итеп,*
*Китәргә иде яшәп.* [3, б.93]

Шагыйрәнең <u>гомер-мәңгелек</u> (38%) мәгънәсеннән башка, <u>гомер-вакыт</u> (25%), <u>гомер-яшәү</u> (25%), <u>гомер-кыскалык</u> (7%), <u>гомер-фасыл</u> (5%) да очрый.

“Гомер” конңепты **Рим Идиятуллин** иҗатында шулай ук ачык күренә. Аның “Хәерле кич!” дигән шигырьләр җыентыгын укып чыккач, шагыйрьнең үзенчәлекле талант иясе, сүз остасы икәненә инанасың. Күренекле шагыйрь Н. Нәҗми Р. Идиятуллин шигърияте турында: “Мин Лермонтов рухын тоям”, — дип яза.

Рим Идиятуллин – Башкортстанда яшәүче татар шагыйре. Аның шигърияте бай, һәм шагыйрь үзенең тирән фикерләү сәләте белән, шигърияттә иң төп аргумент саналган йөрәк януы белән, тирән һәм каршылыклы хисләре белән, шуларның барысын да укучыга җиткерү осталыгы белән үзе булып аерылып тора. Рим Идиятуллинның җыентыгыннан без барлыгы “гомер” компоненты кергән 27 мисал тупладык. Бу мисаллар тулысынча икенче кушымтада күрсәтелгән.

Рим Идиятуллинның шигырьләрендә лирик геройның үз тормышын, үз язмышын ел фасыллары белән чагыштыру күзәтелә. Көз – кеше тормышының иң авыр вакыты. Гомер көзенә кергәч кенә үзеңнең көчсезлегеңне, җир тартуын тою башлана. Көз – сагыш, кеше – бакча, әмма анда нинди генә гөлләр үстерәсен ул үзе сайлый, бакчасын үзе карый...

*Көз каплаган <u>гомер бакчасыннан</u>*
*Караш атсам килер дәвергә,*
*Ачы бер хис очлы хәнҗәр булып*
*Кадала да тора бәгырьгә.* [15, б.35]

Аның һәрбер шигыре диярлек сагыш, үкенү, сагыну белән сугарылган. Ә шигырьләрендә - аның язмышы. Шагыйрь гомерне хушлашудан гына тора дип билгели. Гомер – хушлашу (18%) мәгънәсе аңарда гына очрый, һәм ул

шәхси характерга ия. Гомерендәге беренче хушлашу – туган ягы белән хушлашу.

*Сагыш йөзе таныш түгел чакта*
*Туган ягым белән хушлаштым*
*Һәм каланың салкын ташларына*
*Тузган чабатадан мин бастым.*[ 15, б.95]

Әнкәсен югалту – гомерендәге иң зур югалту.

*Яшәп көйгән әнкәм белән салкын*
*Кабер өсләрендә хушлаштым:*
*Ыңгырашкан зират капкасын да,*
*Шатлык капкасын да шап яптым.*
*Әйт, нәрсә ул яшәү? Безнең – гомер –*
*Соңгы шәме сүнгән мәгарә;*
*Үзем белән үз аңымда чакта*
*Хушлаштырсын Ходай Тәгалә.* [15, б.95].

Шагыйрьдә шулай ук гомер-вакыт (44%), гомер-мәңгелек (33%), гомер-күз (3%), гомер-көн (2%) бәйләнешләре аерылып тора.

Н. Әминева һәм Р. Идиятуллин иҗаты бүгенге татар әдәбияты белән кызыксынучылар өчен бай материал чыганагы ул дип, хаклы рәвештә әйтә алабыз. Ә алар иҗатындагы “гомер” концепты халкыбыз байлыгын тагын да тирәнәйтә, киңәйтә.

# Йомгак

“Татар телендә “гомер” концепты” темасына язылган фәнни-тикшерү эшен тәмамлап шуны әйтә алабыз:

Әйтелгән бер сүз эчендә берничә мәгънә ятарга мөмкин. Лингвокультурология күзлегеннән аның шул күпмәгънәлелеге, мәгънәләр күләме игътибарга лаек. Кешенең көндәлек сүзлегендә никадәр күбрәк сүз булса, аныц рухи дөньясы шулкадәр баерак. Лингвокультурология үзәгендә тел һәм культураны үзендә йөртүче буларак кеше тора һәм төрле культура вәкилләренең аңында салынган дөнья күренеше бертөрле түгел, алардагы мәгънәләр бер бөтен карашлар системасына җыела.

“Концепт” термины “менталь структуралар” термины белән мөнәсәбәттә, ягъни ул культураның субъекты - кеше белән тыгыз бәйләнештә. Концепт терминының бертөрле генә билгеләмәсе юк, чөнки аны төрле өлкәләр өйрәнәләр һәм шул позициядән чыгып билгеләмә бирәләр. Концепт - кеше аңында төп мәдәни оя, семантик берләшмә. Аның структурасында үзәк һәм периферияне аералар. Үзәге - барысына да аңлашылырдай мәгънә, хәтта сүзлек дефинициясе дияргә мөмкин; периферияce - психик, иҗтимагый, мәдәни, милли, шәхсән тәҗрибәдән кергән аңламнар.

Безнең тикшерү объекты булып татар халкының иң төп конңептларның берсе - “гомер” конңепты тора. “Гомер” конңепты үзенә татар халкының дөньяга, яшәү-үлемгә, яшәү максатына карата карашлар системасын туплаган. “Гомер” конңептын репрезентаңияләүче тел һәм сөйләм материаллары халык тарихын, халыкның тормышка мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә.

“Гомер” конңепты милли концепт критерийларына туры килә. Беренчедән, алынма сүз булуына карамастан, *гомер* югары ешлыкка, күпмәгънәлелеккә ия; актив лексика; актив җитештерүче нигезле сүз (*гомер-гомергә, гомеренчә, гомерле, гомерлек, гомерлелек)*. *Гомер* бер составлы атау җөмләнең баш кисәге, шигырь исеме була ала.

Дөнья тел картинасын анализлау өчен паремияләрне, ягъни мәкаль һәм әйтемнәрне анализлау мөһим дип исәплиләр. Шуның өчен без “гомер”

куйдык. Анализлау рус теле белән чагыштырма планда үтәлде. Татар телендә “гомер” сүзе алынма булуына карамастан, өстәмә коннотацияләр белән баетылган, мәкаль-әйтемгә әверелерлек дәрәҗәдә семантик планда халык тарафыннан күптән үзләштерелгән.

Поэтик текстларда без “гомер” конңептының үзәгендәге традиңион мәгънә белән бергә индивидуаль-автор мәгънәләрен дә, периферияне дә ачыкладык. “Гомер” поэтик текст эчендә бик киң, кайчак көтелмәгән мәгънәне белдерә ала. “Гомер” концепты кулланышы буенча Нәҗибә Әминеваның шигъри җыентыгыннан - 50 , Рим Идиятуллинның – 27 - мисал тупладык.

“Гомер” концепты ***Нәҗибә Әминева*** иҗатының төп өлешен биләп тора. Аныц шигырьләрендә кеше гомере фәлсәфәсе ярылып ята. Җыентыгыныц исеме үк, шуңа ишарә. Шагыйрәдә *гомер - мәңгелек* мәгънәсе өстенлек итә, шагыйрәдә шулай ук *кыскалык, вакыт, яшәү, фасыл* константалары аерылып чыга. ***Рим Идиятуллин*** *гомер - вакыт*, *гомер - мәңгелек*, *гомер - күз*, *гомер - көн* бәйләнешләре аерылып тора. *Гомер – хушлашу* мәгънәсе аңарда гына очрый, һәм ул шәхси характерга ия

Шулай итеп, “гомер” концептны тикшерү барышында без аның татар тел дөнья күренешендә мөһим урын алуын, художестволы дөнья күренешен баетуга да зур өлеш кертүен ачыкладык. “Гомер” конңепты халыкның дөньяны танып белү үзенчәлекләрен, яшәү принципларын билгеләргә ярдәм итә.

## Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Арутюнова Н.Д. Язык и мир человека / Н.Д.Арутюнова. - М.: Языки русской культуры, 1999. - 896 с.

2. Аскольдов С.А. Концепт и слово // Русская словесность: От теории словесности к структуре текста: антология/ под ред В.П. Нерознака. - М.: Издательство «Academia», 1997 - с.267-279.

3. Әминева Н.З. Гомер дигән мизгелдә / Н.З. Әминева. – Уфа: Башкортстан “Китап” нәшрияты, 2009. - 224б.

4. Әминева Н.З. Җаным илһамлы чакта / Н.З. Әминева.- Уфа: Башкортстан “Китап” нәшрияты, 2005.- 224б.

5. Әхәтов Г.Х. Татар теленец фразеологик әйтелмәләр сүзлеге / Г.Х. Әхәтов.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1982.-176б.

6. Бабенко Л.Г., Казарин Ю.В. Лингвистический анализ художественного текста. Теория и практика: Учебник; Практикум / Л.Г.Бабенко, Ю.В.Казарин. -М.: Флинта: Наука, 2005. - 496 с.

7. Большой толковый словарь русского языка / Сост. и гл.ред. С.А.Кузнецов. - СПБ.: Норинт, 2000. - 1536 с.

8. Брутян Г.А. Язык и картина мира / Г.А. Брутян // Философские науки. -1973. - №1

9. Вафин М.М. Йөрәгем парәләре: Шигырьләр / М.М. Вафин .- Уфа: Китап, 2007.- 272б.

10. Воробьев В.В., Саяхова Л.Г. Русский язык в диалоге культур/ В.В.Воробьев, Л.Г.Саяхова. - М.: Ладомир, 2006 - 286 с.

11. Головатина В.М. Репрезентация концепта «Вдохновение» в русской литературной традиции / В.М. Головатина. – www/zaart/yandex.ru

12. Жанпеисова Н.М. Репрезентация национальных концептосфер в картине мира казахско-русских билингвов. Автореферат диссертации... доктора филологических наук. - Уфа: Издательство Башкирского университета, 2004. - 42 с.

13. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре / Р.Р. Җамалетдинов. - Казан: Мәгариф, 2006. - 351 б.
14. Иванова С.В. Лингвокультурология и лингвокогнитология: сопряжение парадигм: Учебное пособие. - Уфа: РИО БашГУ, 2004. - 152с.
15. Идиятуллин Р.З. Хәерле кич / Р.З. Идиятуллин.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2007. - 271б.
16. Измайлова Н.Х. Адашкан / Н.Х. Измайлова.- Казан: "Матбугат йорты" нәшрияты, 2000.- 320б.
17. Исәнбәт Н.С. Татар теленен фразеологик сүзлеге. Ике томда. Том 1 / Н.С. Исәнбәт. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989. - 495б.
18. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. Өч томда. Том 2 / Н.С. Исәнбәт.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1963.- 960б.
19. Исмәгыйлева И. Әдип иҗатының "ачкыч"лары / И.Исмәгыйлева // Тулпар. - 2006. - №6 - б.26 - 27.
20. Кобозева И.М. Лингвистическая семантика: Учебное пособие / И.М. Кобозева. - М.: Эдиториал УРСС, 2000. - 352 с.
21. Концепт и культура: Материалы международной научной конференции.- Кемерево: ИПК « Графина», 2003.- 247с.
22. Кубрякова Е.С. Начальные этапы становления когнитивизма: лингвистика - психология - когнитивная наука / Е.С.Кубрякова // Вопросы языкознания. - 1994. - №4
23. Лингвистический энциклопедический словарь. - М.: Большая Российская энциклопедия, 2002. - 709с.
24. Лихачев Д.С. Концептосфера русского языка // Русская словесность: От теории словесности к структуре текста: антология / под ред. В.П.Нерознака. - М.: Издательство «Academia», 1997 - с. 280-287.
25. Магомедова Д.М. Филологический анализ лиричсеского стихотворения / Д.М. Магомедова.- М.: Издательский центр « Академия», 2004. - 208с.
26. Маслова В.А. Лингвокультурология / В.А. Маслова. - М.: Издательский центр «Академия», 2001. - 208 с.

**Краткая аннотация научно-исследовательской работы.**

**Название работы:** «Концепт «жизнь» в татарском языке».

Лингвокультурология как направление в современной лингвистике ориентирована на человеческий фактор в языке и на языковой фактор в человеке. Ее цель – представить системное описание языковой картины мира и обеспечить выполнение образовательных, воспитательных и интеллектуальных задач обучения.

Изучение концептов позволяет выявить национально-культурную специфику языковой картины мира того или иного языкового сообщества, описать менталитет носителей языка посредством анализа языковых средств. Выбор именно концепта «Жизнь» в качестве объекта исследования обусловлен рядом причин. Понимание жизни, отношение к жизни в любой лингвокультуре представляет собой базовый ориентир человеческого поведения, который определяет этноспецифические нормы и стереотипы общения, а также ментальность носителей языка. Концепт «Жизнь» представляет собой сложное ментально-лингвальное образование, отображающее «наивные» представления носителей русского и татарского языка, которые могут быть установлены с помощью лингвокультурологического анализа. Концепт «Жизнь» является одним из базисных концептов, лежащих в основе общего освоения человеком действительности, но, несмотря на свою универсальность, он отличается национально- культурным своеобразием.

**Практическая значимость работы:** полученные результаты могут быть использованы на уроках татарского языка и литературы, а также на уроках русского языка и литературы.